# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

« 07 » 03 2019 ел Яр Чаллы № 819

Тукай муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия һәм эшче төркем төзү турында

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Профилактик эш үткәрү турында» күрсәтмәсе һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясенең 2019 елның 4 февралендәге «Халыкның һәм Татарстан Республикасы территорияләренең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 01-19 санлы карары һәм янгын очракларының артып китүе һәм аларда кешеләрнең һәлак белән бәйле рәвештә,

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия составын расларга (1 кушымта).
2. Тукай муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия нигезләмәсен расларга (2 кушымта).
3. Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җирле үзидарә органнары, социаль өлкә хезмәткәрләре, газ хезмәте һәм идарәче компанияләр хезмәткәрләре катнашында Тукай муниципаль районы территориясендә яшәүче социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең, күп балалы гаиләләрнең, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарның һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтүендә булган гражданнарның йорт хуҗалыкларында газ һәм мич җиһазларының эшкә яраклылыгын тикшерү буенча эшче төркем составын расларга (3 кушымта).
4. 2019 елда эшче төркемгә торак фондының янгын куркынычсызлыгын һәм өлкән яшьтәге гражданнарның, инвалидларның, күп балалы гаиләләрнең һәм социаль куркыныч хәлдә булган балалы гаиләләрнең яшәү шартларын тикшерүне оештырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Гүзәл Юныс кызы Шакировага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның №119 от 04.03.19
карарына 1 кушымта

Тукай муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия составы

**Комиссия составы:**

**Рәис:** Авзалов Ленар Гаяз улы – Башкарма комитет Җитәкчесе.

**Рәис урынбасары:** Шакирова Гузәл Юныс кызы - Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

**Җаваплы секретарь:** Ахунова Эльмира Нурмөхәмәт кызы – Тукай муниципаль районында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы.

**Комиссия әгъзалары:**.

1. Абзалова Илсөяр Хәйдәр кызы - Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары.
2. Хәмәтҗанова Гүзәл Нәсыйх кызы – Башкарма комитетның опека һәм попечительлек секторы мөдире.
3. Нурхәмитова Эльвира Давран кызы – Тукай районы буенча Эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар эше буенча бүлек җитәкчесе.
4. Хөснетдинова Гөлнара Таһир кызы – балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре.
5. Назарова Елена Геннадьевна – Тукай муниципаль районында «Шәфкать» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге мөдире.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның № 819 от 07.03.19 карарына 2 кушымта

Тукай муниципаль районы территориясендә яшәүче социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең, күп балалы гаиләләрнең, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарның һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтүендә булган гражданнарның йорт хуҗалыкларында газ һәм мич җиһазларының эшкә яраклылыгын тикшерү буенча эшче төркем нигезләмәсе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Тукай муниципаль районы территориясендә яшәүче социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең, күп балалы гаиләләрнең, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарның һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтүендә булган гражданнарның йорт хуҗалыкларында газ һәм мич җиһазларының эшкә яраклылыгын тикшерү буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) үз эшчәнлегендә федераль һәм республика норматив хокукый актларына, шулай ук Тукай муниципаль районы норматив хокукый актларына һәм әлеге нигезләмәгә таяна.

2. Эшче төркем составы, аңа үзгәрешләр кертү Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

II. Эшче төркем бурычлары

Эшче төркемнең төп бурычлары:

- гражданнар белән профилактик чаралар үткәрү, аларда торак сектор биналары һәм корылмалары өчен янгын куркынычсызлыгының төп таләпләре аңлатыла;

- халыкның аз керемле катламына (күп балалы гаиләләргә, социаль куркыныч хәлдә булган балалы гаиләләргә, ялгыз һәм өлкән яшьтәге гражданнарга) мич җылыткычларын һәм электр үткәргечләрне ремонтлауда адреслы социаль ярдәм күрсәтү;

- коммуналь хезмәтләр буенча бурычлы, балигъ булмаган балалары булган гаиләләр яшәгән торак йортларны газ, су, электр белән тәэмин итүне туктатмауны контрольдә тоту;

- энергоресурсларга тоташтыру буенча проблемалы мәсьәләләрне ачыклау һәм хәл итү буенча һәм янгын куркынычы барлыкка килүгә китерә торган сәбәпләрне бетерү максатында, торак йортларны 100 процент йөреп чыгуга ирешү;

- янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау, янгын турында автоном белдерү җайланмаларын урнаштыру һәм күп балалы гаиләләрнең, социаль куркыныч хәлдә булган балалы гаиләләрнең торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларын түләү өчен финанс средстволарын эзләү.

III. Эшче төркем вәкаләтләре

1. Эшче төркем хокуклы:

- эшче төркем алдында куелган бурычларны хәл итү өчен, җирле үзидарә органнары структур бүлекчәләреннән, тармак оешмалары һәм предприятиеләрдән билгеләнгән тәртиптә кирәкле мәгълүматларны һәм материалларны соратып алырга;

- эшче төркем әгъзаларына аның эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча йөкләмәләр бирергә;

- кирәк булган очракта, торак-коммуналь хезмәтләр алдында бурычларны киметү мәсьәләләрен хәл итү өчен, билгеләнгән тәртиптә оешма, предприятиеләрне (алар белән килешү буенча) җәлеп итәргә.

IV. Эшче төркем эшчәнлеге тәртибе

1. Эше төркем эшчәнлеге юнәлешләре буенча проблемаларны өйрәнү һәм фикер алышу, шулай ук Тукай муниципаль районында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча аерым мәсьәләләрне карау.

2. Тукай муниципаль районы территориясендә эшче төркем эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча программаларны һәм инициативаларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр эшләү.

3. Эшче төркем алдында куелган бурычларны үтәү кирәк булганда, эшче төркем утырышларын чакыру һәм үткәрү.

4. Эшче төркем утырышын уздыру датасы һәм урыны турында мәгълүмат, утырыш көн тәртибе һәм эшче төркем утырышында карала торган мәсьәләләр буенча материаллар эшче төркемнең барлык әгъзаларына, шулай ук утырышка чакырылган башка затларга утырыш үткәрү датасына ике көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

5. Эшче төркем утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала.

6. Эшче төркем әгъзасы:

- шәхсән (алмаштыру хокукыннан башка) эшче төркем утырышларында катнаша;

- кирәк булганда, эшче төркемнең җаваплы секретаренә эшче төркем утырышларының көн тәртибе мәсьәләләре буенча үз фикерен язмача юллый;

- эшче төркем җитәкчесе йөкләмәләрен үти.

7. Эшче төркем әгъзасының утырышта шәхсән катнашырга мөмкинлеге булмаган очракта, ул утырышта карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча үзенең язма тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен җибәрергә хокуклы.

8. Эшче төркем карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавыш тигез булган очракта, эшче төркем җитәкчесе тавышы хәлиткеч булып тора.

9. Эшче төркем карарлары эшче төркемнең җаваплы секретаре тарафыннан хәзерләнә һәм эшче төркем җитәкчесе (ә ул булмаганда - эшче төркем

җитәкчесе күрсәтмәсе буенча билгеләнгән зат) кул куя торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

10. Эшче төркемнең җаваплы секретаре эшче төркем утырышларын үткәрүне оештыра, эшче төркем утырышы көн тәртибе проектларын хәзерләүне тәэмин итә, эшче төркем әгъзаларына утырышларны үткәрү датасы һәм урыны турында хәбәр итә, карарлар хәзерли һәм аларның үтәлешен контрольдә тота, эшче төркем утырышларының беркетмәләрен алып бара һәм саклый.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның № 119 от 04.03.19
карарына 3 кушымта

Тукай муниципаль районы территориясендә яшәүче социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең, күп балалы гаиләләрнең, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарның һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтүендә булган гражданнарның йорт хуҗалыкларында газ һәм мич җиһазларының эшкә яраклылыгын тикшерү буенча эшче төркем составы

**Эшче төркем составы:**

1. Сухорук Александр Александрович – Тукай муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр бүлеге башлыгы

2. ТР Янгын сагы дәүләт учреждениесе башлыгы
   - Фәрдиев Рамил Рәис улы – Биклән авылы
   - Нәфыйков Ришат Рөстәм улы – Комсомолец поселогы
   - Лебедев Игорь Вячеславович – Күзкәй авылы
   - Вәлиев Наил Җәмил улы – Теләнче Тамак авыл җирлеге
   -
3. «Челныгаз» эксплуатация-җитештерү идарәсе башлыгы – Галиев Мөнәвир Инсаф улы
4. Авыл җирлекләре башлыклары:
   1. Фазылҗанов Марат Габделхәй улы – Әҗмәкәй авыл җирлеге
   2. Ионычев Максим Александрович – Бәтке авыл җирлеге
   3. Сәхбиев Мансур Шакирҗан улы – Бикән авыл җирлеге
   4. Камилҗанов Зарифъян Мәхмүт улы – Боерган авыл җирлеге
   5. Абдульманова Роза Николаевна – Борды авыл җирлеге
   6. Гарифуллина Гөлнара Сәүбан кызы – Иштирәк авыл җирлеге
   7. Габдуллина Рәвия Касыйм кызы – Калмаш авыл җирлеге
   8. Гилфанов Нияз Рәшит улы – Калмия авыл җирлеге
   9. Белова Тамара Ивановна – Кенәз авыл җирлеге
   10. Сурова Ольга Викторовна – Комсомол авыл җирлеге
   11. Гәрәев Эдуард Рәкыйп улы – Күзкәй авыл җирлеге
   12. Низамиева Эльмира Роберт кызы – Круглое Поле авыл җирлеге
   13. Даутов Адель Гомәр улы – Кече Шилнә авыл җирлеге
   14. Артемьев Валентин Иванович – Мәләкәс авыл җирлеге
   15. Аглязова Фәридә Әхмәт кызы – Мусабай-Завод авыл җирлеге
   16. Усманов И.М. – Сәмәкәй авыл җирлеге
   17. Ихсанов Флер Гаяз улы – Түбән Суыксу авыл җирлеге
   18. Волкова Рима Рәис кызы – Яңа Троицкий авыл җирлеге
   19. Сафина Резеда Хасият кызы – Иске Абдул авыл җирлеге
   20. Дусадбеков Равис Миңнехәмәт улы - Иске Дөреш авыл җирлеге

21. Нәҗметдинов Рамил Шарипҗан улы – Теләнче Тамак авыл җирлеге
22. Гончарова Ольга Анатольевна – Шилнәбаш авыл җирлеге
23. Сәгыйтдинов Мансур Сәхәбетдин улы – Яңа Бүләк авыл җирлеге

5. Торак милекчеләре ширкәте рәисләре:

   1. Хафизова Флера Фәгыйть кызы (килешү буенча) – «Татарстан» торак милекчеләре ширкәте рәисе

   2. Вафин Рамил Шамил улы (килешү буенча) – «Нефтебаза» торак милекчеләре ширкәте рәисе

6. Идарәче компанияләр директорлары:
   1. Мараджабова Рида Бикмөхәммәт кызы – «Надежда МКД» ИК директоры
   2. Харисова Татьяна Владимировна – «Тамерлан» ИК директоры
   3. Игнатьева Вера Корбангали кызы – «Доверие» ИК директоры

7. Юмагулов Рустам Наил уы – начальник ФГКУ «15 отряд ФПС по РТ».

8. Полиция вәкаләтле участок хезмәткәрләре:
   1. Нәбиуллин Илнур Салихҗан улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 1 нче административ участок
   2. Моратов Ренат Рамил улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 2 нче административ участок
   3. Габдуллин Нур Таһир улы – полиция вәкаләтле участок өлкән хезмәткәре, 3 нче административ участок
   4. Мөхәмәтшин Айрат Хәйдәр улы – полиция вәкаләтле участок өлкән хезмәткәре, 4 нче административ участок
   5. Мөхәмәтшин Айрат Хәйдәр улы – полиция вәкаләтле участок өлкән хезмәткәре, 5 нче административ участок
   6. Вәсилов Альмир Илсур улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 6 нчы административ участок
   7. Вәсилов Альмир Илсур улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 7 нче административ участок
   8. Насыйбуллин Радик Марсель улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 8 нче административ участок
   9. Сәлмәнов Илнур Габит улы – полиция вәкаләтле участок өлкән хезмәткәре, 9 нчы административ участок
   10. Шәябтдинов Айрат Айдар улы – полиция вәкаләтле участок өлкән хезмәткәре, 10 нчы административ участок
   11. Вәгыйзов Илдар Салихҗан улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 11 нче административ участок
   12. Ишмакаев Рамис Әсхәт улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 12 нче административ участок

13. Әхмәтханов Илнар Альберт улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 13 нче административ участок
14. Әхмәтханов Илнар Альберт улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 15 нче административ участок
15. Җиһаншин Рамил Фәрит улы – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 15 нче административ участок
16. Хөрмәтова Алиса Витальевна – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 16 нче административ участок
17. Мозаффаров Нияз Илдус улы – полиция вәкаләтле участок өлкән хезмәткәре, 17 нче административ участок
18. Васюткин Евгений Викторович – полиция вәкаләтле участок хезмәткәре, 19 нчы административ участок
19. Ямбулатов Наил Сәит улы – полиция вәкаләтле участок өлкән хезмәткәре, 20 нче административ участок